СОВЕТ
СТАРОКАКЕРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КӘКЕРЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

Иске Кәкерле авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 30 январе № 25/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 24 апрелендагы 31/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары, Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, акчалата

бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 24 апрель 31/1 номерлы (25.05.2018 № 32/2, 20.09.2018 № 38/1, 07.11.2018 №42/3, 28.01.2019 №45/2, 13.11.2020 №3/4, 12.10.2022 №22/4 редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **1 нче Кушымта таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ ДАИМИ НИГЕЗДӘ БИЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРГА,ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ**

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Авыл җирлеге Башлыгы | | | | 17 390,00»; |

**2)** «Авыл җирлекләре булып торучы муниципаль берәмлекләр башлыкларына айлык акчалата бүләкләүдән тыш, муниципаль берәмлекләр башлыклары өчен хезмәткә түләүнең 12 төркеменә кергән муниципаль берәмлекләр башлыклары өчен кертелгән Муниципаль берәмлекләр башлыклары өчен айлык акчалата бүләк – елына 6,72 айлык акчалата бүләк»дигән **абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Авыл җирлекләре булып торучы муниципаль берәмлекләр башлыкларына, айлык акчалата бүләкләүдән тыш, айлык акчалата бүләк түләнә:

- хезмәткә түләүнең 12 төркеменә кертелгәннәр-елына 9,26 айлык акчалата бүләк.»

3) **2 нче Кушымта** таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ**

| | Вазыйфаларның исеме | Хезмәт хакы | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| 1. | Башкарма комитет Җитәкчесе | 20 682,00 | | |
| 2. | Башкарма комитет секретаре | | | 16 875,00». |

**5) 6 нчы кушымтада** «Муниципаль район муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру күләмнәрен һәм тәртибен»дә «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Иске Кәкерле җирлеге башлыгы: Р.Ф.Фаткуллин